Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Советы КАРАРЫ

2019 нчы елның 25 нче октябре 266№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Советының 2016 нчы елның 15 нче декабрендәге
73 номерлы “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе
турындагы Нигезләмә хакында" гы карарына
үзгәрешләр кертү турында

2001 нче елның 21 нче декабрендәге 178-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" Федераль закон, 2015 нче елның 29 нчы июнендәге 180-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон, 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 1Э1-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, 2009 нчы елның 1 нче апрелендәге 45-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" Федераль закон, Татарстан Республикасы “Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2016 нчы елның 15 нче декабрендәге 73 номерлы “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмә хакында" гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче бүлектәге 6 нчы пунктта “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль милекне сату өчен билгеләнгән тәртиптә махсус оешмалар җәлеп итәргә хокуклы” сүзләрен төшереп калдырырга;

2 нче бүлегендәге 6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле 2 нче абзац өстәргә:

"Җирле үзидарә органы үз карарлары белән әлеге статьяның 1 пунктындагы 8.1 пунктчасында күрсәтелгән юридик затларга милекче исеменнән билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштырыла торган, субъектлар милкендә булган мөлкәтне сатуны оештырырга Һәм (яки) мондый мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашыруны йөкли”;

-1 нче бүлекнең 3нче пунктында “Федераль закон” сүзләреннән соң “2001 нче елның 21 нче декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон" сүзләрен өстәргә”;

2.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы Никошин А.Ф.